УПРАВЛЕНИЕ
ПО ОХРАНЕ И
ИСПОЛЬЗОВАНИЮ
ОБЪЕКТОВ
ЖИВОТНОГО МИРА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫ
ОБЪЕКТЛАРЫН САКЛАУ
ҺӘМ АЛАРДАН
ФАЙДАЛАНУ ИДАРӘСЕ

**Приказ** **Боерык**

15.02.2016 Казан № 20-од

Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән, чит ил дәүләтенең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен кабул итү тәртибе турында Кагыйдәнамәне раслау турында

2004 елның 27 июленнән 79-ФЗ номерлы “Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында”гы Федераль канун белән, 2015 елның 10 октябреннән 506 номерлы “Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын алмаштыра торган затлар белән, чит ил дәүләтенең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый оешмаларның һәм бүтән оешмаларның мактаулы һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен һәм башка аерма билгеләрен кабул итү тәртибе турында Кагыйдәнамәне раслау турында”гы Россия Федерациясе Президенты Боерыгы белән тәңгәл килеп, 2016 елның 12 гыйнварыннан УП-5 номерлы “Татарстан Республикасының аерым, аларга билгеләү һәм алардан азат итү Татарстан Республикасы Президенты белән башкарыла торган, дәүләт вазыйфаларын алмаштыручы затлар белән, чит ил дәүләтенең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый оешмаларның һәм бүтән оешмаларның мактаулы һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен һәм башка аерма билгеләрен кабул итү тәртибе турында Кагыйдәнамәне раслау турында”гы Татарстан Республикасы Президенты Боерыгы белән тәңгәл килеп **б о е р а м:**

1. Кушымтада бирелгән Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән, чит ил дәүләтенең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен кабул итү тәртибе турында Кагыйдәнамәне расларга(алга таба – Кагыйдәнамә)

2. Хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлекләрен куллануны тикшерү бүлегенең алдынгы консультанты О.А. Филипповага Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендәге Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен бу боерык белән таныштырырга.

3. Бу боерыкның үтәлүе артыннан тикшерүне Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе башлыгының урынбасары Ю.Б. Матвеевка тапшырырга.

Идарә башлыгы Ф.С.Батков

15.02.2016 елдан 20-од номерлы
Татарстан республикасының
хайваннар дөньясы объектларын
саклау һәм файдалану Идарәсе
боерыгы белән расланды

Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән, чит ил дәүләтенең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен кабул итү тәртибе турында
Кагыйдәнамә

1. Бу Кагыйдәнамә Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә, вазифаи бурычлары буенча күрсәтелгән оешмалар белән үзара бәйләнештә булган очракта, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре (алга таба- гражданлык хезмәткәре, Идарә) белән, чит ил дәүләтенең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус ( фәннидән башка) дәрәҗәләрен, бүләкләрен кабул (алга таба – дәрәҗәләр, бүләкләр) итү тәртибен регламентлаштыра.

2. Гражданлык хезмәткәре дәрәҗәләр, бүләкләр алган вакытта, Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе башлыгының ( алга таба – Идарә башлыгы) рөхсәтен алырга тиеш.

3. Дәрәҗә, бүләк алган яки аны тиздән алу турында чит ил дәүләтеннән, халыкара оешмадан, сәяси партиядән, башка иҗтимагый һәм дини оешмадан белдерү кәгазе алган гражданлык хезмәткәре, өч көн эчендә кадрлар хезмәтенә, чит ил дәүләтенең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен кабул итәргә рөхсәт сорау турында, бу Кагыйдәнамәнең 1нче Кушымтасында күрсәтелгән рәвеш буенча, үтенеч язуы бирә ( алга таба –үтенеч язуы).

Бу Кагыйдәнамәнең 8 бүлекчәсе белән туры китереп, кадрлар хезмәте үтенеч язуын теркәгәннән соң, аны карау вакыты ун эш көне тәшкил итә.

4. Дәрәҗәдән, бүләктән баш тарткан гражданлык хезмәткәре, өч көн эчендә кадрлар хезмәтенә, чит ил дәүләтенең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус дәрәҗәләреннән, бүләкләреннән баш тарту турында, бу Кагыйдәнамәнең 2 нче Кушымтасында күрсәтелгән рәвеш буенча, белдерү кәгазе бирә ( алга таба – белдерү кәгазе).

5. Үтенеч язуын тикшерү нәтиҗәләре буенча, Идарә башлыгы карар чыгарганчыга кадәр, дәрәҗәне, бүләкне алган гражданлык хезмәткәре, дәрәҗәнең төп документларын, бүләкне һәм аның төп документларын, җаваплы саклауга кадрлар хезмәтенә, аларны алганнан соң, өч көн эчендә тапшыра. Шул ук вакытта,

бу Кагыйдәнамәнең 2 нче Кушымтасында күрсәтелгән рәвеш буенча, алу-бирү акты төзелә.

6. Әгәр дә гражданлык хезмәткәре дәрәҗәне, бүләкне эш буенча командировкада булган вакытта алган, яки алардан баш тарткан очракта, үтенеч язуын яки белдерү кәгазен бирү вакыты, гражданлык хезмәткәре командировкадан кайткан көннән исәпләнә.

7. Гражданлык хезмәткәре, үтенеч язуын яки белдерү кәгазен, дәрәҗәнең төп документларын, бүләкне һәм аның төп документларын, бу Кагыйдәнамәнең 3-5 бүлекчәләрендә күрсәтелгән вакытта, аннан тормаган сәбәп буенча, бирә алмаган очракта, ул үтенеч язуын яки белдерү кәгазен, дәрәҗәнең төп документларын, бүләкне һәм аның төп документларын, андый сәбәпләр беткәннән соң, икенче эш көнән дә соңармыйча тапшырырга тиеш.

8. Үтенеч язуын (белдерү кәгазен) теркәү, кадрлар хезмәте белән, аның керү көнендә, бу Кагыйдәнамәнең 4 нче Кушымтасында күрсәтелгән рәвеш буенча, теркәү китабында үтәлә. Теркәлгән үтенеч язуын (белдерү кәгазен) кадрлар хезмәте ике эш көнендә Идарә башлыгына тикшерүгә җибәрә.

9. Кадрлар хезмәте ике эш көнендә, гражданлык хезмәткәрен Идарә башлыгыгының үтенеч язуын тикшерү нәтиҗәсе буенча чыгарган карары белән таныштыра һәм аңа имза астына, кадрлар хезмәте мөһере белән расланган, Идарә башлыгының резолюциясе белән үтенеч язуының (белдерү кәгазенең) күчермәсен тапшыра. Идарә башлыгының резолюциясе белән үтенеч язуының (белдерү кәгазенең) төп нөсхәсе гражданлык хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлә.

10. Идарә башлыгы гражданлык хезмәткәренең, бу Кагыйдәнамәнең 5 нче бүлекчәсендә күрсәтелгән, үтенеч язуын канәгатьләндергән очракта, кадрлар хезмәте дәрәҗәнең төп документларының, бүләкнең һәм аның төп документларының төп нөсхәләрен ун эш көне эчендә гражданлык хезмәткәренә бирә.

Шул ук вакытта, бу Кагыйдәнамәнең 3 нче Кушымтасында күрсәтелгән рәвеш буенча, алу-бирү акты төзелә.

11. Идарә башлыгы гражданлык хезмәткәренең, бу Кагыйдәнамәнең 5 нче бүлекчәсендә күрсәтелгән, үтенеч язуын канәгатьләндермәгән очракта, кадрлар хезмәте дәрәҗәнең төп документларының, бүләкнең һәм аның төп документларының төп нөсхәләрен ун эш көне эчендә чит ил дәүләтенең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый һәм дини оешмаларның туры килүче әгъзаларына юнәлтә.

Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән, чит ил дәүләтенең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен кабул итү тәртибе турындагы Кагыйдәнамәгә 1нче кушымта

Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе башлыгына

______________________________

______________________________

______________________________
(Исем, фамилия, атасының исеме, вазифа)

**Чит ил дәүләтенең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен кабул итәргә рөхсәт алу турында үтенеч язуы.**

________________________________________________________________
(мактаулы һәм махсус дәрәҗәнең исеме, бүләкләр)

________________________________________________________________
( нинди күрсәткән хезмәт өчен бирелде һәм кем белән, нинди күрсәтелгән хезмәт өчен бүләкләнде һәм кем белән)

________________________________________________________________
(мактаулы һәм махсус дәрәҗәнең, бүләкнең документларын бирү вакыты һәм урыны)

алырга рөхсәт итүегезне сорыйм.

Дәрәҗәнең төп документларын, бүләкне һәм аның төп документларын
( кирәклесенең астына сызарга)

________________________________________________________________
(мактаулы һәм махсус дәрәҗәнең исеме, бүләкләр)

________________________________________________________________
(мактаулы һәм махсус дәрәҗәнең исеменә, бүләкләргә документлар исемлеге)

“__”_________ елдан №___________ алу-бирү акты буенча Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсенең кадрлар хезмәтенә тапшырылды.

«___» ______________ 20__ ел ____________ ________________________
(имза) (имзаны чишү)

Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт граждандлык хезмәткәрләре белән, чит ил дәүләтенең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен кабул итү тәртибе турындагы Кагыйдәнамәгә 2 нче кушымта

Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсе башлыгына

________________________________

________________________________

________________________________

(Исем, фамилия, атасының исеме, вазифа)

**Чит ил дәүләтенең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус дәрәҗәләреннән, бүләкләреннән баш тарту турында белдерү кәгазе.**

________________________________________________________________

(мактаулы һәм махсус дәрәҗәнең исеме, бүләкләр)

________________________________________________________________

( нинди күрсәткән хезмәт өчен бирелде һәм кем белән, нинди күрсәтелгән хезмәт өчен бүләкләнде һәм кем белән)

алудан баш тарту турында карар кабул итүне белдерәм.

«___» ______________ 20__ ел ____________ ____________________

(имза) (имзаны чишү)

Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән, чит ил дәүләтенең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен кабул итү тәртибе турындагы Кагыйдәнамәгә 3 нче кушымта

**Алу-бирү акты.**

« »_____________20___ел №_________

Без, аста имза куйганнар, киләсе эчтәлекле акт төзедек:
_______________________________________________________

_______________________________________________________
(Исем, фамилия, атасының исеме, вазифа)

бирдек/алдык ( кирәклесенең астына сызарга), ә Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсенең кадрлар хезмәтенең _______________________________ _________________________
(шәхеснең исем, фамилиясе, атасының исеме, вазифасы)

рәсми шәхесе түбәндәгене алды/бирде ( кирәклесенең астына сызарга)

| № | Исеме | Саны (данә.) | Тасвирлама |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |

Бирде

_______________________________
(имза) (имзаны чишү)

Алды

_______________________________
(имза) (имзаны чишү)

Татарстан республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану Идарәсендә Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән, чит ил дәүләтенең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый һәм дини оешмаларның мактаулы һәм махсус дәрәҗәләрен, бүләкләрен кабул итү тәртибе турындагы Кагыйдәнамәгә 4 нче кушымта

## Үтенеч язуын (белдерү кәгазен) теркәү китабы

| № | Үтенеч язуын (белдерү кәгазен) биргән граждан-лык хез-мәткәре-нең исем, фамилия-се, атасы-ның семе | Үтенеч язуын (белдерү кәгазен) биргән граждан-лык хез-мәткәре-нең | Үтенеч язуының (белдерү кәгазенең) бирелү вакыты | Бүләкнең, дәрәҗәнең исеме | Алу-бирү актының реквизит-лары (булган очракта) | Үтенеч язуын (белдерү кәгазен) кабул иткән затның имзасы, исеме, фамилиясе, атасының исеме | Үтенеч язуын (белдерү кәгазен) тапшырган затның имзасы, исеме, фамилиясе, атасының исеме | Идарә башлыгының карары турында мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | |